ГЛАВА
НАДЕЖДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НАДЕЖДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 ноябрь , 2024 ел Надеждино авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Надеждино авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 25 ноябрenә 11 сәг 00 минутка Надеждино авылы, Клуб урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан «Күп функцияле үзәк» зданиясендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авылында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2024 елның 25 ноябрenә 14 сәгать 00 минутка Надеждино авылы, Набережная урамы, 8 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Надеждино торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының **икенче этабын** билгеләргә.
3. 2024 елның 26 ноябрenә 10 сәг 00 минутка Надеждино авылы, Клуб урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан «Күп функцияле үзәк» зданиясендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***өченче этабын*** билгеләргә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Надеждино авыл җирлеге Надеждино авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Савельева